**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

11.04.2020 № 142

**«Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Попечительләр Советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы органнары составын раслау турында» 2016 елның 26 мартындагы 217 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 8 декабрендәге 701 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 185 номерлы, 2019 елның 15 мартындагы 123 номерлы һәм 2019 елның 27 ноябрендәге 395 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Попечительләр Советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Попечительләр Советы составыннан И.Ә. Фәйзуллинны, А.А. Фоминны чыгарырга;

Попечительләр Советы составына кертергә:

Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улын – «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директорын;

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

Попечительләр Советы әгъзасы З.Р. Вәлиеваның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**